Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы торак пунктында үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

23 нче ноябрь 2022 нче ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми ринциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы “Иске Кыязлы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, Иске Кыязлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендә кабул ителгән 89 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турындагы” Карары нигезендә Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы торак пунктында 2022 нче елның 23 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: “2023 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, мобилизацияләнүчеләрнең гаилә әгъзалары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллануга ризамы:

**1.Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Иске Кыязлы торак пунктындагы Ленин, Яшьләр, М.Җәлил, Гагарин урамнарын төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

- Кышын торак пункт юлларын кардан чистарту.

**2. Территорияне төзекләндерү.**

-Иске Кыязлы авылы өчен балалар мәйданчыгы сатып алу һәм аны урнаштыру;

-башкарма комитеттракторына КУН(төягеч) сатып алу;

-үзәктәге агачларның ботакларын кыскарту(эшне башкарган өчен түләү, пычкыга запас частьләр , ГСМ алу)

**“РИЗА” “КАРШЫ” “ТОТКАРЛАНУЧЫ”**

Җыен беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 584 кеше теркәлгән, җыенда катнашып, тавыш биргән кешеләр саны-309.

Җыенда катнашучыларның кул күтәреп тавыш бирүләре нәтиҗәсендә тавышлар түбәндәгечә билгеләнде:

“Риза” дип 309 кеше тавыш биргән
“Каршы” дип 0 кеше тавыш биргән
“Тоткарланучы” 0 кеше.

Алда китерелгән мәгүлуматлар нигезендә халык җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы торак пунктында үткәрелгән халык җыенын уздырылган дип, җыен нәтиҗәләрен -дөрес дип исәпләргә.

2. Җыенда күтәрелгән түбәндәге мәсьәлә буенча чыгарылган карарны кабул итәргә: “2023 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге составына керүче Иске Кыязлы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлар, мобилизацияләнүчеләрнең гаилә әгъзалары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны җирле әһәмияткә ия түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә куллануга ризамы:

**1.Торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү:**

-Иске Кыязлы торак пунктындагы Ленин, Яшьләр, М.Җәлил, Гагарин урамнарын төзекләндерү(балчык белән күтәртү, вак таш сатып алу һәм җәю, торбалар сатып алу);

- Кышын торак пункт юлларын кардан чистарту.

**2. Территорияне төзекләндерү.**

-Иске Кыязлы авылы өчен балалар мәйданчыгы сатып алу һәм аны урнаштыру;

-башкарма комитеттракторына КУН(төягеч) сатып алу;

-үзәктәге агачларның ботакларын кыскарту(эшне башкарган өчен түләү, пычкыга запас частьләр , ГСМ алу)

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Карарны Татарстан Республикасының норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Дәүләтшин